Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы Зур
Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Зур Мәшләк авылы 2025 елның 17 январе

Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгының
2024 елгы хисабы һәм 2025 елга бурычлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5, 5.1 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 7, 7.1 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы 2024 елдагы хисабы һәм 2025 елга бурычлар турындагы хисабын игътибарга алырга.
2. 2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары алдына түбәндәге бурычлар куярга :
- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- рөхсәтсез барлыкка китерелгән чүплекләрне юк итү.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы: Шәмсевәлиев М.М.